**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет ур., 13

**СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**14 февраль 2024 ел** **№ 89**

**Красносельский авыл җирлеге Советының 2017 елның 20 октябрендәге 64 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрТатарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнашу һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы, нигезендә, Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Красносельский авыл җирлеге Советының 2017 елның 20 октябрендәге 64 нче номерлы карары белән расланган (2022 елның 7 апрелендәге 48 нче номерлы Совет карары редакциясендә) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрТатарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнашу һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән бастырып чыгару өчен бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне рәсми сайтка урнаштыру авыл җирлегенең башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә, ул килешү буенча районның кадрлар хезмәтенә (кадрлар хезмәте бүлекчәсенә, кадрлар эше һәм муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча белгечкә) белешмәләр тапшыра (алга таба - кадрлар хезмәте).»

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Әлеге тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән белешмәләр, затның биләве үз артыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр урнаштыруга китергән муниципаль вазыйфаны биләгән бөтен чор эчендә, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнашкан.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru адрес буенча интернет челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Красносельский авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф. Хисаметдинов